**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУТЛУ-БУКАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422665, с. Кутлу-Букаш,
ул. Советская, дом 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КОТЛЫ-БӨКӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422665, Котлы-Бөкәш авылы,
Совет урамы, 32 нче йорт,

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, Kbuk.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 17 августы** **Котлы Бөкәш авылы** **№ _29__**

Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының “2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында " 2018 елның 14 июнендәге 23 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 7 августындагы 16086508201800007 номерлы хокукый экспертиза бәяләмәсе нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты, 3,4 өлеше, 48 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында» 2018 ел, 14 июнь, 23 нче карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм

Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында  һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Г.Г.Нәҗипов
Котлы Бөкәш  авыл җирлеге Башлыгы